**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «25» маеннан

№ 22-173

«2021 елда «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы аша кергән гаризаларны (хәбәрнамәләрне) карау нәтиҗәләре турында»

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнарының «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге кысаларында гражданнарның, дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм җирле үзидарә органнарының электрон хезмәттәшлеге турында» 2012 елның 10 августындагы 676 номерлы карары нигезендә һәм 2021 елда «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы аша кергән гаризаларны (хәбәрнамәләрне) карау нәтиҗәләре турында Яңа Чишмә муниципаль районы Советының гомуми бүлеге башлыгы докладын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елда «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы аша кергән гаризаларны (хәбәрнамәләрне) карау нәтиҗәләре турында мәгълүматны игътибарга алырга.
2. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә, оешма һәм учреждение җитәкчеләренә «Халык контроле»Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы аша кергән гаризаларны (хәбәрнамәләрне) карау буенча үз вакытында карарлар кабул итәргә тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов